ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 26 ноябрендә
кабул ителде

## 1 статья

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7; № 10; 2014, № 1 – 2, № 5; № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.14 статья өстәргә:

“2.14 статья. **Тартмый торган тәмәке әйберләре белән Татарстан Республикасы территориясендә күпләп һәм ваклап сәүдә итүне тыюны бозу**

Тартмый торган тәмәке әйберләре белән Татарстан Республикасы территориясендә күпләп һәм ваклап сәүдә итүне тыюны бозган өчен –

гражданнарга бер меңнән алып ике мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – өч меңнән алып дүрт мең сумга кадәр; юридик затларга егерме меңнән алып утыз мең сумга кадәр административ штраф салына.”;

2) 7.1 статьяда “2.11 – 2.13” саннарын “2.11 – 2.14” саннарына алмаштырырга;

3) 8.1 статьяның 2 өлешендә “2.5,” саннарыннан соң “2.14,” саннарын өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 18 декабре
№ 128-ТРЗ